КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 май г.Казань № 344

2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2030 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясен (алга таба – Стратегия) расларга.
2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына җавап бирә торган өлкәдәге программаларны һәм проектларны эшләгәндә Стратегия нигезләмәләренә таянып эш итәргә.
3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль программаларны һәм проектларны эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Стратегия нигезләмәләрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин